**Студентларның практикасын оештыру һәм үткәрү турында _......__ номерлы шартнамә**

Казан шәһәре «___» _______________ _____ ел

Алга таба **«Университет»** дип аталучы, 2016 елның 30 декабрендәге 01-10/367 номерлы ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче Идарә, икътисад һәм финанс институты директоры Бәһаветдинова Наилә Гомәр кызы йөзендә, бер яктан, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автономияле белем бирү учреждениесе һәм алга таба **«Башкарма комитет»** дип аталучы, «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ, шәһәр Уставы нигезендә эш итүче, Башкарма комитет Җитәкчесе Салахов Фәрид Шавкат улы йөзендә, икенче яктан, бергә **Яклар** дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне төзеделәр:

## 1. Шартнамәнең предметы

1.1. Әлеге шартнамә «Россия Федерациясендә белем бирү турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелде һәм Университет студентларының практикасын оештыру һәм үткәрү тәртибен җайга сала.

1.2. Әлеге шартнамә нигезендә Башкарма комитет Университет студентларының практика үтүләрен оештыру бурычын үз өстенә ала.

## 2. Якларның бурычлары

2.1. Башкарма комитет бурычлы:

2.1.1. Студентларның Башкарма комитет бүлекчәләрендә уза торган практикасына җитәкчелек итүгә квалификацияле белгечләрне билгеләргә.

2.1.2. Студентларга әзерлек (белгечлек) юнәлеше буенча белем алу өчен кирәкле шартларны тудырырга.

2.1.3. Студентларның әзерлек (белгечлек) юнәлешенә мөнәсәбәте булмаган урыннарда (вазыйфаларда) эшләвенә юл куймаска.

2.1.4. Студентларга практика программаларын үтәү өчен кирәкле шартларны, шул исәптән һәр эш урынында куркынычсыз эш шартларын тәэмин итәргә.

2.1.5. Хезмәтне саклау буенча мәҗбүри инструктажлар үткәрергә: гомумән һәм эш урынында билгеләнгән документларны рәсмиләштереп; кирәк булган очракларда, студентларны куркынычсыз эш алымнарына өйрәтергә.

2.1.6. Студентларның хезмәт дисциплинасын һәм Башкарма комитетта гамәлдә булган эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен бозу очраклары турында Университетка хәбәр итәргә.

2.1.7. Практика тәмамлангач, практика үткән һәр студентка ул әзерләгән хисапның сыйфатын чагылдырып, характеристика бирергә.

2.2. Университет бурычлы:

2.2.1. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автономияле югары белем бирү учреждениесе студентларын производство, диплом алды практикасына җибәрергә.

2.2.2. Студентларның практика җитәкчесен профессор-укытучылар составына караган үз хезмәткәрләре арасыннан билгеләргә.

2.2.3. Башкарма комитетка практика башланганчы 10 көннән дә соңга калмый, практикага (практиканың төрен һәм срогын күрсәтеп) җибәрелә торган студентлар исемлеген (юлламасын) тапшырырга.

2.2.4. Студентларның хезмәт дисциплинасын һәм Башкарма комитет хезмәткәрләре өчен мәҗбүри булган эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен үтәүләрен тәэмин итәргә.

**3. Якларның җаваплылыгы һәм форс-мажор хәлләре**

3.1. Әлеге шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар әлеге шартнамәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган җаваплылыкны үз өстенә ала.

3.2. Яклар әлеге шартнамә буенча йөкләмәләрне өлешчә яки тулысынча үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә, әгәр бу – әлеге шартнамә төзелгәннән соң гадәттән тыш характердагы, җиңә алмаслык хәлләр, Якларның алдан күзалламавы яки булдыра алмавы нәтиҗәсендә барлыкка килгән булса.

3.3. Әлеге шартнамәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән хәлләр килеп чыкканда, һәр Як, озакка сузмыйча, алар турында язма рәвештә икенче Якка хәбәр итәргә тиеш.

Бу хәбәрдә хәлләрнең характеры турында мәгълүмат, шулай ук бу хәлләрнең булуын раслаучы һәм, мөмкин булса, аларның әлеге шартнамә буенча үз йөкләмәләрен үтәү мөмкинлегенә йогынтысын бәяләүче рәсми документлар булырга тиеш.

3.4. Әлеге шартнамәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән хәлләр килеп чыккан очракта, әлеге шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәү вакыты әлеге хәлләр һәм аларның нәтиҗәләре гамәлдә булган вакытка туры китереп күчерелә.

3.5. Әгәр әлеге шартнамәнең 3.2 пунктында санап үтелгән хәлләр һәм аларның нәтиҗәләре ике айдан артык гамәлдә булса, Яклар, әлеге шартнамәне үтәүнең альтернатив ысулларын ачыклау өчен, өстәмә сөйләшүләр үткәрә.

**4. Бәхәсләрне хәл итү**

4.1. Әлеге шартнамә шартларын үтәгәндә барлыкка килергә мөмкин булган барлык бәхәсләр һәм аңлашылмаучылыкларны Яклар сөйләшүләр юлы белән хәл итәргә омтылалар

4.2. Сөйләшүләр юлы белән җайга салынмаган бәхәсләр, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгәнчә, суд тәртибендә хәл ителә.

**5. Шартнамәнең гамәлдә булу срогы. Шартнамәне үзгәртү һәм өзү тәртибе**

5.1. Әлеге шартнамә ике Як тарафыннан имзаланган көннән башлап үз көченә керә һәм 5 ел эчендә гамәлдә була.

5.2. Әгәр Якларның берсе дә шартнамәне озайтуга карата 1 айдан соңга

калмый каршылык белдермәсә, әлеге шартнамә автомат рәвештә киләсе 5 елга озайтыла.

5.3. Якларның килешүе буенча әлеге шартнамә үзгәртелергә яки өзелергә мөмкин.

Һәр Як әлеге шартнамәне берьяклы рәвештә, бу хакта икенче Якка 30 көн алдан хәбәр итеп, өзәргә хокуклы. Шул ук вакытта әлеге шартнамәне берьяклы өзү студентларга карата бурычларны туктатуга китерми.

## 6. Якларның реквизитлары һәм имзалары

| **Университет:**<br>КФУ ФДАЮББУ | **Башкарма комитет:**<br>«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ |
|---|---|
| 420008, РФ, РТ, Казан шәһәре,<br>Кремлевская урамы, 18<br>ОГРН 1021602841391<br>ИНН 1655018018, КПП 165501001<br>р/с 40503810100024000001<br>к/с 30101810000000000805<br>«Ак Барс» ААЖ Казан шәһ. Банкы<br>БИК 049205805, ОКТМО 92701000001<br><br>Институт директоры<br><br>_______________ / Н.Г. Баһаветдинова<br>М.П. | 423805, РФ, ТР, Яр Чаллы шәһәре,<br>Хәсән Туфан проспекты, 23<br>ИНН: 1650135166/165001001<br><br>Башкарма комитет Җитәкчесе<br><br>______________________________/ Ф.Ш. Салахов<br>М.У. |